**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлегенең Кече Кайбыч торак пунктында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

24 нче октябрь 2019 ел № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлегенең Кече Кайбыч торак пунктында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2020 нче елда үзара салым акчаларын Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авылҗирлеге территориясендә даими яшәүче һәм яшә үурыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 (бишйөз) сум күләмендә алып барырга.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

*а) җирлек территориясен төзеклəндерүне оештыру:*

- материаллар сатып алып, урам утларын ремонтлау;
- җирлектәге торак пунктлардагы чүплекләрне чистарту;

*б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- материаллар сатып алып, сууткәргеч челтәрләрен ремонтлау;

*в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

*г) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;*

- материаллар сатып алып, ритуаль хезмәтләр күрсәтү бинасын төзү;;
- материаллар сатып алып зиратларны чистарту һәм ремонтлау.»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Ябалак авыл җирлеге Башлыгы М.Ф.Гыйзәтуллина